КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 3 июль г.Казань № 539

Массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендәге оешмаларга Татарстан Республикасының мәгълүмат киңлеген үстерү, шул исәптән аның инфраструктурасын камилләштерү, республикада мәгълүмат технологияләре базарын үстерү, гражданлык җәмгыятен формалаштыруда массакүләм мәгълүмат чаралары ролен арттыру, республика турында, шул исәптән инвестицион җәлеп итүчәнлек турында уңай мәгълүмат формалаштыру һәм аны Россия Федерациясенең барлык территориясе буенча һәм аннан читтә тарату, халыкка бирелә торган мәгълүматның сыйфатын яхшырту һәм оперативлыгын арттыру, Татарстан Республикасындагы ике дәүләт теленең тигез хокуклылыгын тәэмин итү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендәге оешмаларга Татарстан Республикасының мәгълүмат киңлеген үстерү, шул исәптән аның инфраструктурасын камилләштерү, республикада мәгълүмат технологияләре базарын үстерү, гражданлык җәмгыятен формалаштыруда массакүләм мәгълүмат чаралары ролен арттыру, республика турында, шул исәптән инвестицион җәлеп итүчәнлек турында уңай мәгълүмат формалаштыру һәм аны Россия Федерациясенең

барлык территориясе буенча һәм аннан читтә тарату, халыкка бирелә торган мәгълүматның сыйфатын яхшырту һәм оперативлыгын арттыру, Татарстан Республикасындагы ике дәүләт теленең тигез хокуклылыгын тәэмин итү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин